РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЮТАЗИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АБСАЛЯМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
423957, Республика Татарстан,
Ютазинский район, с.Абсалямово,
ул. Молодежная д.2
тел./факс: 4-26-79
E-mail: Absal.Utz@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423957,Татарстан Республикасы,
Ютазы районы, Әбсәләм авылы,
Яшьләр урамы, 2
тел./факс: 4-26-79
E-mail: Absal.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИE** **КАРАР**

**№ 8** **«23» август 2024 ел**

Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Башкарма комитеты карарының үз көчен югалтуын тану турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль канун, 2020 елның 23 декабрендәге «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләр чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында»гы 2220 санлы карар, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы канун, Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 ноябрендәге 29 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 04 мартындагы «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якын чикләрне билгеләү турында»гы 7 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Әбсәләм авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән мизгелдән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева